ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

24 01 2020 г. № 27

2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә даими пассажирлар ташуны Планлаштыру документын раслау турында

2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә авто-мобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә, карар бирәм:

1. 2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәренең даими пассажирлар ташуны Планлаштыру документын расларга (кушымта).

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге җитәкчесенә (Камелина М.В.) әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Р. Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 24-нче гыйнвар
27-нче номерлы карары белән расланган
кушымта

2020-2022 еллар чорына Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Түбән Кама шәһәренең даими пассажирлар ташуны планлаштыру
ДОКУМЕНТЫ

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль маршрутлар буенча даими автобуста пассажирлар ташуны оештыру өлкәсендә озак вакытлы сәясәтнең гомуми нигезләмәләре.

1.1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә даими пассажирлар ташуны планлаштыру буенча әлеге документ (алга таба – Планлаштыру документы) 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими ташуны оештыру» (алга таба - 220-ФЗ номерлы Федераль закон) Федераль закон һәм 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими ташуны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законны гамәлгә ашыру хакында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнгән.

1.2. Планлаштыру документы халыкның транспорт хезмәтләренә ихтыяҗын канәгатьләндерүне, муниципаль аралыкта Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре халкына транспорт хезмәте күрсәтүне оештыруны һәм оптимальләштерүне, хезмәт күрсәтүнең культурасын һәм сыйфатын күтәрүне, 2020 елдан 2022 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә даими муниципаль пассажирлар ташуны үстерү чараларының юнәлешләрен һәм исемлеген билгеләүгә юнәлдерелгән.

1.3. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә 2020-2022 елларда муниципаль маршрутлар буенча даими автобусларда пассажирлар ташуны үстерү максаты булып, социаль, икътисадый, экологик һәм башка факторларны исәпкә алып, халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын күтәрү.

1.4. Планлаштыру документында 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» Федераль законы, 220-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән төшенчәләр кулланыла.

1.5. Муниципаль маршрутларны оештыру өлкәсендә өстенлекле юнәлеш булып, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре халкының күрсәтелә торган хезмәтләрнең югары сыйфатын тәэмин итү шартларында даими рәвештә пассажирлар ташуга булган ихтыяҗын канәгатьләндерү тора. Әлеге максатны тормышка ашыру транспорт хезмәте күрсәтүне үстерүнең түбәндәге бурычларына ирешүне күздә тота:

- даими пассажирлар ташу муниципаль маршрутларының, транспорт чаралары классларының һәм хәрәкәт составының оптималь челтәрен формалаштыру;

- муниципаль маршрутлар эшчәнлеген тәэмин итү өчен, транспорт инфраструктурасы объектларын үстерү һәм камилләштерү;

- даими пассажирлар ташу муниципаль маршрутлары буенча күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренең сыйфатын күтәрү;

- халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәренә караган гражданнарны ташу өчен билгеләнгән шәһәр җәмәгать транспортының заманчарак күчмә составын сатып алу (түбән идәнлеләр);

- заказчыга пассажирлар йөргән өчен түләүнең 100% ын күчерүне күздә тоткан контрактларга күчү (брутто-контрактлар).

1.6. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә даими автобуста пассажирлар ташуның оптималь маршрут челтәрен формалаштыру, даими пассажирлар ташуның яңа муниципаль маршрутларын да кертеп, пассажирлар агымын, даими ташуның муниципаль маршрутларына ихтыяҗны, шәһәрне комплекслы төзү һәм үстерү планнарын анализлау нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.7. Чараларны башкару процессы өч этапка бүленә:

- I этап – 01.2020 елдан 12.2020 елга кадәр;

- II этап – 01.2021 елдан 12.2021 елга кадәр;

- III этап – 01.2022 елдан 12.2022 елга кадәр.

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль маршрутлар буенча даими автобусларда ташуны оештыруның хәзерге торышы һәм проблемалары.

2.1. Түбән Кама муниципаль районында, халык ихтыяҗлары нигезендә, 10 шәһәр автобусы һәм 7 трамвай маршруты оештырылган һәм эшли.

2.2. Барлык маршрутлар буенча да пассажирлар ташу җайга салынулы тарифлар буенча, йөрү буенча барлык ташламалар да биреп башкарыла.

2.3. Муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар ташуны гамәлгә ашыручы күчмә составның гомуми саны якынча 75 берәмлек (зур класслы автобуслар) һәм 60 берәмлек (трамвайлар) тәшкил итә.

2.4. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә автомобиль транспортында даими ташу маршрутлары буенча пассажирлар ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик классы Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 18 июлендәге 221 номерлы «Татарстан Республикасы территориясе буенча пассажирлар һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик

характеристикаларын раслау турында» боерыгы белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

2.5. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль маршрутлар буенча даими автобусларда пассажирлар ташуның торышына анализ күрсәткәнчә, соңгы елларда даими рәвештә пассажирлар ташуны оештыруда кайбер проблемалар барлыкка килүгә китергән даими рәвештә пассажирлар ташу өлкәсендә кайбер үзгәрешләр булды:

- пассажирлар ташу куркынычсызлыгын киметүгә һәм әйләнә-тирә мохитне пычратуга китерә муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары искерү һәм техник торышы начараю;

- күп кенә муниципаль маршрутларда пассажир транспорт чаралары йөрү юлларының туры килүе, бу юл челтәреннән нәтиҗәсез файдалануга, транспорт чараларының бер юнәлештә күп микъдарда тупланууына, пассажирлар ташу куркынычсызлыгын киметүгә китерә;

- даими пассажирлар ташу өлкәсендә норматив-хокукый актлар таләпләрен бозу фактлары белән раслана торган пассажирлар ташучылар арасында транспорт дисциплинасы кимү.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль маршрутлар буенча даими автобуста пассажирлар ташу өлкәсендә килеп туган хәл алга таба камилләштерүне һәм үстерүне таләп итә.

3. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль маршрутлар буенча даими автобус йөртүне үстерү чаралары исемлеге.

Куелган бурычларга муниципаль маршрутлар буенча даими пассажирлар ташуны үстерү буенча комплекслы чаралар үткәреп ирешелә.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә 2020-2022 елларга муниципаль маршрутлар буенча даими автобуста пассажирлар ташуны үстерү бурычларын түбәндәге чаралар уздыру юлы белән тормышка ашыру планлаштырыла:

3.1. I этапта:

3.1.1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәренең гомуми файдаланудагы шәһәр пассажир транспортының маршрут челтәренә тикшерү үткәрү, аны оптимизацияләү буенча тәкъдимнәр эшләү.

Гамәлдәге автобус паркын уңайлырак һәм сыйдырышлырак, шул исәптән түбән идәнлеләр исәбенә яңарту буенча пассажирлар ташучылар белән эшләү.

3.1.2. Юл йөрү өчен бердәм түләү системасын булдыру.

3.1.3. Даими рәвештә пассажирлар ташу маршрутлары буенча транспорт чараларының бару юлын үзгәртү.

3.1.4. Вахта һәм шәһәр маршрутларын бердәм челтәргә берләштерү

3.2. II этапта:

3.2.1. Гамәлдәге автобус паркын уңайлырак һәм сыйдырышлырак, шул исәптән түбән идәнлеләр исәбенә яңарту буенча пассажирлар ташучылар белән эшләүне дәвам итү.

3.2.2. Транспорт белән идарә итүнең автоматлаштырылган системаларының заманча программа комплексларын гамәлгә кертү һәм алып бару юлы белән пассажирлар транспорты белән идарә итү системасын камилләштерү.

3.2.3. Эре пассажирлар туктау пунктларын электрон табло рәвешендәге маршрутларның мәгълүмати күрсәткечләре белән җиһазландыру.

3.2.4. Җәмәгать транспортының яңа тукталыш пунктларын файдалануга тапшыру буенча эшләр башкару.

3.2.5. Шәһәр һәм вахта маршрутларын бердәм челтәргә берләштерү.

3.3. III этапта:

3.3.1. Муниципаль маршрутлар эшчәнлеген тәэмин итү өчен транспорт инфраструктурасы объектларын үстерү һәм камилләштерү.

3.3.2. Заказ бирүчегә пассажирлар йөргән өчен түләүнең 100% ын күчерүне күздә тоткан контрактларга күчү (брутто-контрактлар).

3.4. Куелган бурычларны тормышка ашыру барышында, Планлаштыру документына 1 нче кушымта нигезендә, транспорт хезмәте күрсәтүне үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру планлаштырыла.

3.5. Транспорт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булып тора:

- муниципаль маршрутларда ташу мөмкинлеген арттыру;
- муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар ташу күләмен арттыру;
- муниципаль маршрутлар буенча автобуслар хәрәкәте расписаниесен үтәү проценты.

3.6. Муниципаль маршрутлар эшчәнлеген тәэмин итү өчен объектлар һәм транспорт инфраструктурасы объектларының үсеш күрсәткечләре булып тора:

- башлангыч һәм (яки) ахыргы тукталыш пунктлары сыйфатында даими пассажирлар ташу муниципаль маршрутлары буенча кулланырга рөхсәт ителә торган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә урнашкан тукталыш пунктлары исемлегенә объектларны кертү өчен бирелгән гаризалар саны;
- башлангыч һәм (яки) ахыргы тукталыш пунктлары сыйфатында даими пассажирлар ташу муниципаль маршрутлары буенча кулланырга рөхсәт ителә торган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә урнашкан тукталыш пунктлары исемлегенә кертелгән объектлар саны.

3.7. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре халкы өчен муниципаль маршрутлар буенча күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренең сыйфатын арттыру күрсәткечләре булып, Түбән Кама шәһәре территориясендә халыкка муниципаль транспорт турында (транспорт төре, расписание, арадаш тукталышлар һ. б.) хәбәр итүнең бердәм системасын булдыру һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль маршрутлар буенча рейсларга электрон билетлар сату системасын үстерү тора, шул исәптән мобиль җайланмалар өчен кушымталар булдыру һәм үстерү.

3.8. Планлаштыру документын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелек күрсәткечләре системасы Планлаштыру документына 2 нче кушымтада китерелгән.

3.9. 2020 елга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә даими пассажирлар ташу муниципаль маршруты

буенча пассажирлар йөртү хокукына ачык конкурслар үткәрү чоры планлаштыру документына 3 нче кушымтада күрсәтелгән. Ачык конкурс 220-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үткәрелә.

3.10. Чараларны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре:

- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәренең муниципаль маршрутлары буенча даими пассажирлар ташу куркынычсызлыгын арттыру;
- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре пассажир автомобиль транспортының уңайлылыгын, комфортлылыгын һәм җәлеп итүчәнлеген арттыру;
- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре халкының даими рәвештә пассажирлар ташуга булган ихтыяҗын канәгатьләндерү;
- муниципаль маршрутларның хәрәкәт составын яңарту;
- халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәренә караган гражданнар өчен пассажир автомобиль транспортыннан файдалану мөмкинлеген арттыру;
- даими пассажирлар ташу өлкәсендә заманча мәгълүмати технологияләр кертү.

2020-2022 еллар чорына Татарстан
Республикасы Түбән Кама муниципаль
районы Түбән Кама шәһәре территориясендә
даими пассажирлар ташуны Планлаштыру
документына
1-нче кушымта

Транспорт хезмәте күрсәтүне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар

| т\с | Чара исеме | Үтәү срогы |
|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә даими пассажирлар ташу буенча муниципаль маршрутлар реестрына үзгәрешләр кертү | 220-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган үзгәрешләр кертү өчен нигезләр барлыкка килгән саен |
| 2 | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы, Түбән Кама шәһәре территориясендә даими пассажирлар ташу муниципаль маршрутына үзгәрешләр керткән очракта, маршрут карталарын бирү | 220-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, пассажирлар ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирү турында пассажир ташучыларның гаризалары кергән саен |
| 3 | Җайга салынулы тарифлар буенча даими пассажирлар ташу муниципаль маршрутларына пассажир ташучыларга маршрут карталары бирү | 220-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә даими |
| 4 | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә даими рәвештә пассажирлар ташу буенча муниципаль автобус маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында җайга салынулы тарифлар буенча муниципаль контрактлар төзү | «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә 220-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кирәк булган саен |

2020-2022 еллар чорына Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә даими пассажирлар ташуны Планлаштыру документына 2-нче кушымта

Планлаштыру документын тормышка ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре таблицасы

| т/с | Бурычлар һәм максатчан күрсәткечләр исеме | Үлчәү берәмлеге | Транспорт хезмәте күрсәтүне үстерү нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләре кыйммәте |
|---|---|---|---|
| 1 | «Даими пассажирлар ташуның муниципаль маршрутлары челтәрен, транспорт чаралары классларын һәм хәрәкәт составы санын оптимальләштерү» | | 2022 ел |
| 1.1 | Муниципаль аралыкта рәсми маршрутларда пассажирлар ташу мөмкинлеген арттыру | % | 15 |
| 1.2 | Муниципаль аралыкта маршрутларда пассажирлар ташу күләмен арттыру | % | 22 |
| 1.3 | Расписаниене үтәү | % | 87 |
| 2 | «Муниципаль маршрутлар эшчәнлеген тәэмин итү өчен транспорт инфраструктурасы объектларын үстерү» | | |
| 2.1 | Даими пассажирлар ташуның муниципаль маршрутлары буенча башлангыч һәм (яки) ахыргы тукталыш пунктлары сыйфатында кулланырга рөхсәт ителә торган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә урнашкан тукталыш пунктлары исемлегенә объектларны кертү өчен бирелгән гаризалар саны; | берәм. | 5 |
| 2.2 | Башлангыч һәм (яки) ахыргы тукталыш пунктлары сыйфатында даими пассажирлар ташу муниципаль маршрутлары буенча кулланырга рөхсәт ителә торган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә урнашкан тукталыш пунктлары исемлегенә кертелгән объектлар саны. | берәм. | 5 |

| т/с | Бурычлар һәм максатчан күрсәткечләр исеме | Үлчәү берәмлеге | Транспорт хезмәте күрсәтүне үстерү нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләре кыйммәте |
|---|---|---|---|
| 3 | «Даими пассажирлар ташу муниципаль маршрутлары буенча күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренең сыйфатын арттыру» | | |
| 3.1 | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль транспорт турында халыкка хәбәр итүнең бердәм системасын (транспорт төре, расписание, арадаш тукталышлар һ.б.) булдыру. | берәм. | 1 |

2020-2022 еллар чорына Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре территориясендә даими пассажирлар ташуны Планлаштыру документына
3-нче кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре территориясендә җайга салынулы тарифлар буенча даими автобуста пассажирлар ташу муниципаль маршрутлары буенча муниципаль контрактлар төзү

ГРАФИГЫ

| Маршрутның теркәлү номеры | Маршрутның тәртип номеры һәм исеме | Планлаштырылган муниципаль контракт төзү датасы |
|---|---|---|
| 1 | № 1 «Урман – ТЭЦ1 – Урман» | 28.02.2020 ел |
| 2 | № 2 «ДЕПО – Красный ключ – ДЕПО» | 28.02.2020 ел |
| 3 | № 3 «Урман – Шин заводы – Урман» | 28.02.2020 ел |
| 4 | № 5 «Урман – ТЭЦ2 – Урман» | 28.02.2020 ел |
| 5 | № 6 «ДЕПО – Урман – ДЕПО» | 28.02.2020 ел |
| 6 | № 7 «Урман – БСИ – Урман» | 28.02.2020 ел |
| 7 | № 8 «Красный Ключ – БСИ – Красный Ключ» | 28.02.2020 ел |
| 8 | № 1 «Автовокзал – әйләнеш» | 29.05.2020 ел |
| 9 | № 5 «Автовокзал – әйләнеш» | 29.05.2020 ел |
| 10 | № 5А «Автовокзал – әйләнеш» | 29.05.2020 ел |
| 11 | № 10 «Автовокзал – әйләнеш» | 29.05.2020 ел |
| 12 | № 25 «Автовокзал – әйләнеш» | 29.05.2020 ел |
| 13 | № 34 «34мкр. – Гайнуллин – әйләнеш» | 29.05.2020 ел |
| 14 | № 55 «ТККҮ – әйләнеш» | 29.05.2020 ел |
| 15 | № 56 «Автовокзал – әйләнеш» | 29.05.2020 ел |
| 16 | № 59 «ТККҮ – әйләнеш» | 29.05.2020 ел |
| 17 | № 47 «ТККҮ – 2 нче шәһәр хастаханәсе - ТККҮ» | 29.05.2020 ел |

Искәрмә: * Контракт ел саен 1 елга төзелә.